| Каралган | Килешенгән | Раслыйм |
| --- | --- | --- |
| МБ житәкчесе<br>_____ /Нәҗметдинова Л.Ә./<br>Беркетмә № 1<br>«25»август 2014 ел. | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең УТЭБДУ<br>_____ /Сәгъдиева Г.Ф./<br>«25»август 2014 ел. | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең директоры<br>_____ / Әхмәд[illegible]<br>Приказ № 94<br>«27»август 2014 ел. |

Уку фәненнән

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы

“Яңа Мәлкән ТГБМ” ГББМУ

Нәҗметдинова Ләлә Әсхәт кызы, икенче квалификацион категорияле укытучы

татар әдәбияты, 6 нчы сыйныф

Педагогик совет
утырышында каралган
беркетмә № 1
« 25 »август 2014 ел.

2014 – 2015 нче уку елы

**Аңлатма язуы**

**6 нче сыйныфта** татар әдәбиятыннан эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1. 2012 нче елның 29 нчы декабреннән гамәлгә кергән“РФ дә Мәгариф турында”273 нче федераль кануны (“Закон об образовании в РФ” )
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турындагы кануны.
3. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы.
4. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теле һәм әдәбиятыннан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 933/14 нче №лы боерыгы белән расланган урнәк программа
5. “Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен татар әдәбиятыннан программа” (5-9 нчы сыйныфлар) Төзүче авторлар: Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2013 ел.
6. Ф.А.ГаниеваМ.Д., Гарифуллина төзегән “Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләренең 6 нчы сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан авторлык (эш) программасы (Казан, 2014 нче ел)
7. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында”гы 17291/14 №лы хаты (04.09.2014.)
8. ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган базис уку-укыту планы (2012 нче ел)
9. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның 2014/15 нче уку елына уку-укыту планнары (25.08.2014 нче ел датасы белән чыгарылган 91 нче № лы боерык);
10. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның уку фәннәреннән эш программасын төзү турындагы положениесе (Положение о рабочей программе учебного предмета, курса, дисциплины (модуля) МБОУ «Новомелькенская ООШ» Мензелинского муниципального района РТ)

**Укыту предметының әһәмияте һәм роле**

Гомуми төп белем бирә торган мәктәпләрдә татар әдәбияты предметы укучыларга әдәби белем бирүне, әдәби әсәрне, язучы иҗатын аңлау өчен кирәкле иҗади һәм теоретик күнекмәләр формалаштыруны, милли мәдәниятка кагылышлы мәгълүматлар җиткерүне үз эченәала. Урта сыйныфларда әдәбиятны укытуның **төп максаты** булып матур әдәбият әсәрләрен форма һәм эчтәлек берлегендә аңларга һәм анализларга өйрәтү, логик фикерләү сәләтен үстерү һәм камилләштерү, балаларның рухи дөньяларын баету тора. Бу процесс өч – гамәли, гомуми белем бирү, тәрбияви - яссылыкларны берләштереп алып барылырга тиеш. Әлеге максат түбәндәге **бурычларны** алга куя:

укучының төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белүенә ирешү һәм анализ барышында кулланырга күнектерү;

укучыда матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру;

укучының телдән һәм язма сөйләмен үстерү;

укучыда үз милләтенә, аның әдәбиятына, мәдәниятенә карата хөрмәт, дөньяга гуманлы караш, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, үз милләтенең, шушы төбәктә яшәүче башка халыкларның мәдәни кыйммәтләренә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Урта сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **гомуми (метапредмет) нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыда әдәби әсәрне аңлап укырлык, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү;
- сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итәргә өйрәтү;

- язу һәм сөйләм осталыгын үстерү, мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли, үз фикерен дәлилли, кирәк икән – үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белергә, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алырга һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләргә күнектерү;
- баланың үз эшчәнлеген һәм әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүенә, мөстәкыйль карарлар кабул итә һәм аларны җиренә җиткереп үти алуына ирешү;
- төрле чыганаклар белән эшләргә, аларны табарга, мөстәкыйль рәвештә кулланырга, төркемләргә, чагыштырырга, анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.

**Татар әдәбияты дәресләренең урыны**

Региональ базис укыту планында татар әдәбияты фәнен укытуга 350 сәгать каралган, шуның 70 сәгате (атнага 2 сәгать) 6 нчы сыйныфта татар әдәбиятын укыту өчен бирелә. Татар мәктәбенең **6 нчы сыйныфында** татар әдәбияты дәресләре программа нигезендә атнага 2 дәрес исәбеннән барлыгы 70 сәгатькә каралган.

ТР Минзәлә муниципаль районы МБГББУ “Яңа Мәлкән төп гомуми белем бирү мәктәбе”нең 2014-2015 елгы укыту планында да 70 дәрес (атнага 2 сәгать) бирелгән. Эш программасы шуларга нигезләнеп 70 дәрес (атнага 2 сәгать) исәбеннән төзелде. Программада “Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләре өчен (5-9) татар әдәбиятыннан үрнәк программа файдаланылды һәм аның ярдәмендә темаларга үзгәреш кертелде.

Татар мәктәпләрендә татар әдәбияты фәнен укыту буенча УМК юк. Ф.Ә.Ганиева, М.Д.Гарифуллина. Әдәбият. 6 сыйныф. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014 ел дәреслеге буенча укытыла

**ӘДӘБИЯТ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ**

Урта сыйныфларда әдәбият укыту әдәби мирасның иң камил әсәрләре, аерым язучылар иҗаты белән укып танышу һәм аларны өйрәнү, тикшерү–анализлау һәм нәтиҗәләр ясауга, бәяләүгә йөз тота. Укучыларда язучыларның тормышы, иҗаты турында (биографик), әдәбият тарихы, аның төрле этаплары, аерым чорлар әдәбиятының йөзен билгеләгән әсәрләр, язучылар турында өстәмә, әдәби әсәрне, иҗатны тирәнтен анализлау өчен кирәк булган өстәмә теоретик, әдәби әсәрне чор белән бәйләп характерлаучы, чорның сыйфатларын, төп кыйммәтләрен табу өчен кирәкле мәгълүматларның туплануы мөһим.

Урта сыйныфларда татар әдәбиятының аерым чорлары үзара бәйләнешле өйрәнелә башлый, аерым фольклор үрнәкләре, аларга анализ аша поэтик-фәлсәфи йөкләмәне, эчке, субъектив мәгънәне табу күнекмәләре формалаштырыла – болар әдәби иҗатка карата күзаллау булдыруда катнаша. Әдәби үрнәкләр белән танышу эше өч төрдә алып барыла: аерым әдәби әсәрләр уку һәм анализлау, аерым берләре укып фикер алышу, кайберләре сыйныфтан тыш уку өчен тәкъдим ителә. Әмма һәр очракта да алда куелган критерий һәм таләпләр истә тотыла.

**Әдәбият тарихы**

***Әдәбият тарихын*** өйрәнү халык авыз иҗатыннан башлана.

**Халык авыз иҗаты**

Халыкның милли, рухи мәдәният хәзинәсе буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләренең үзенчәлекле сыйфатлары, аларда гомумкешелек кыйммәтләренең зур урын тотуы. Халык авыз иҗатында образлар бирелеше. Фольклорда дөнья сурәте: каһарманлык, яхшылык һәм явызлык, яшәеш һәм кеше, кеше һәм табигать хакында күзаллаулар.

Халык иҗатының язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынты ясавы. Фольклорның төп жанрлары. Әкиятләр, жанрлык сыйфатлары, жанр төрләре. Җыр жанрына хас сыйфатлар. Җырларны төркемләү. Татар халык җырларына хас үзенчәлекләр. Көй һәм сүз. Кыска жанрлар: табышмаклар, мәзәкләр, мәкальләр һәм әйтемнәр. Бәетләр. Риваятьләр һәм легендалар, аларга хас үзенчәлекләр. Мифлар. Мифларның килеп чыгышы хакындагы карашлар. Мифларны төркемләү. Татар халык мифлары. Дастан жанрына хас сыйфатлар.

Халык авыз иҗаты поэтикасы (фантастик яки мифологик сюжет һәм детальләрдәге чынбарлыкка охшату; сурәтләү чаралары буларак кабатлау, каршылык, чиктән тыш арттыру, кечерәйтү, чагыштыру һ.б.). Татар халык авыз иҗатының башка халыклар фольклоры белән аваздашлыгы һәм аермалы яклары.

Әәбиятның барлыкка килүе, татар әдәбиятының фольклор һәм ислам мифологиясе белән бәйләнешләре. Фольклор жанрларының әдәбиятка күчүе.

**Борынгы, урта гасырлар һәм XIX гасыр татар әдәбияты**

Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятының шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Тотрыклы мотивлар: гадел идарәче, мәрхәмәтлелек, игелекле исем–ат, әхлаклылык, камил инсан һ.б. Урта гасырлар әдәбиятында романтик мотивлар. Үгет–нәсыйхәтчелек.

Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Аңлы-белемле, мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. Сүз сәнгатендә яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Бу чор әдәбиятында төп тема һәм мотивлар буларак аң-белем, мәгърифәт, әхлак, тәрбия. Татар милләтенең уяныргa, үсәргә тиешлеге, хатын-кыз язмышы, алдынгы, бигрәк тә рус мәдәниятенә йөз тоту кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше.

**XX йөз — XXI йөз башы татар әдәбияты**

XX гасыр башында сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу.

1920-1930 елларда әдәбиятның каршылыклы үсеше. Традицияләрне дәвам итүче әсәрләр. Яңа тормыш төзү хакында сөйләүче әсәрләр. Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка тәэсире. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте.

XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Азатлык, шәхес ирекe, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы.

XX-XXI гасыр чигендә татар әдәбиятының тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу. Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау.

Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар.

**Әдәбият теориясе**

**Әдәби төр һәм жанрлар.** Эпос, лирика һәм драма төрләре. Жанр. «Жанр хәтере». Эпик жанрлар: роман, повесть, хикәя. Лирик жанрлар: пейзаж лирикасы, гражданлык лирикасы, күңел лирикасы, фәлсәфи лирика. Шәркый жанрлар системасы. Драма жанрлары: комедия, трагедия, драма. Лиро-эпик жанрлар: сюжетлы шигырь, мәсәл, баллада, нәсер, поэма. Төрара формалар: сәяхәтнамә.

**Сәнгать төре буларак әдәбият**. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы.

**Әдәби әсәрдәге образлылык.** Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Лирик герой, хикәяләүче, лирик “мин”, автор образы, автор позициясе. Табигать образы, әйбер образы, мифологик образ, фантастик образ, архетип.

**Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма.** Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт, хронотоп. Текст: эпиграф, багышлау, кәчле позиция.

**Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль.** Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Әдәби сөйләм: хикәяләү, сөйләшү (диалог), сөйләү (монолог). Лирик чигенешләр. Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа. Шигырь төзелеше. Көлке: юмор, сатира, сарказм, шарж. Язучы стиле: көлке, тәнкыйди, фаҗигале, экзистенциаль, публицистик һ.б. башлангычлар.

**Әдәбият тарихы.** Традицияләр, яңачалык. Дини әдәбият, дөньяви әдәбият.

**Әдәби барыш.** Әдәби процесс (барыш); чор әдәбияты.

**Күнекмәләр формалаштыру**

- Укучыга билгеле бер күләмдә белем бирү белән янәшә, аларны ныгыту, күнекмә дәрәҗәсендә беркетү кирәк була. Әдәбият шикелле белемнәр анализлау-тикшерү барышында үзләштерелә торган предмет өчен бу аерата мөһим. **Күнекмәләр булдыру** эшчәнлеге түбәндәге юнәлешләрдәүстерелә һәм бәяләнә:

- - **рецептив эшчәнлек**: әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан сөйләү; сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәрнең төрен, жанрын билгеләү һәм фикерне исбатлау.

- - **репродуктив эшчәнлек**: әдәби әсәрнең сюжетын, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, характерларны аңлатып бирә, бәяли алу; төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү; вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алу.

- - **иҗади эшчәнлек**: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьле укый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; рольләргә кереп кабатлап бирү; план төзү һәм әсәрләр турында бәяләмә язу, сочинение элементлары белән изложение язу; әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язу.

- - **эзләнү эшчәнлеге**: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; әдәби әсәргә, аның өлешләренә, язучы иҗатына карата аңлатмалар, бәя бирү.

- - **тикшеренү эшчәнлеге**: әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализлау; тулы текстны анализлау; төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү; әсәрләрне үзара чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны таба белү; язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү.

| № | Темалар | Әсәрләрне өйрәнү | Дәрестән тыш уку | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Әдәбият теориясе |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Эш программасындагы сәгать саны | | | |
| 1. | Халык авыз иҗаты. | 3 | | | |
| 2 | «Алып кешеләр», «Җил иясе җил чыгара» мифлары. | | | | Миф турында төшенчә. |
| 3 | **Практик дәрес. Тема:** Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма. | 2 | | | |
| 4 | **К.Насыйри.** «Әбүгалисина» повесте. | 4 | | | Хыялый хикәя |
| 5 | **БСҮ. Сочинение.** К.Насыйриның «Әбүгалисина» повесте буенча язма эш. | | | 1 | Гаделлек һәм белем турында сочинение язу. |
| 6 | **Г.Ибраһимов.** «Алмачуар» хикәясе | 5 | | | Хикәя жанры, төзелеше. |
| 7 | **Г.Рәхим.** «Яз әкиятләре» хикәясе. | 2 | | | |
| 8 | **Дәрдемәнд.** «Видагъ»,“Каләмгә хитаб” | 2 | | | Шигырь төзелеше. |
| 9 | **С.Рәмиев “Уку”, “Авыл” шигырьләре** | 2 | | | |
| 10 | **Г.Камал.** «Беренче театр» комедиясе. | 4 | | | Драматургия жанры. |
| 11 | **Г.Тукайның** «Исемдә калганнар» истәлеге. | 5 | | | Автобиографик әсәр. |
| 12 | **БСҮ. Сочинение** “Бәләкәй Апуш ничек зур Тукай улды?” | | | 2 | Тукайның кешелеклелегенә сокланырлык |
| 13 | **Практик дәрес. Тема:** Лирик жанрлар: пейзаж лирикасы; табигать образлары. | 2 | | | Пейзаж лирикасы; табигать образлары. |
| 14 | **Һ. Такташ.** “Урман”, “Пи-би-бип”, ”Болай гади җыр гына” шигырьләре | 4 | | | |
| 15 | **И.Газиның** «Кояш артыннан киткән тургай” хикәясе. | 3 | | | Конфликт турында төшенчә. |
| 16 | **ДТУ. И.Гази**. “Өч Мәхмүт” хикәясе. | | 1 | | |
| 17 | **Р.Батулла**. «Имче», “Көчек”,”Чагыр” хикәяләре. | 4 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 18 | **БСҮ. Р.Батулланың** «Имче» әсәренә нигезләнеп сочинение язу. | | | 1 | |
| 19 | **Ф.Яруллинның** “Ак төнбоек” хикәясе**.** | 3 | | | |
| 20 | **ДТУ. Ф.Яруллин**. “Урман әкияте” хикәясе. | | 1 | | «Имче» әсәренә нигезләнеп сочинение язу. |
| 21 | **Р.Миңнуллин** шигырьләре. | 3 | | | |
| 22 | **М.Җәлил.** «Сандугач һәм чишмә» балладасы. | 2 | | | Баллада турында төшенчә |
| 23 | **ДТУ.М.Җәлил**. “Ана бәйрәме” шигыре | | 1 | | |
| 24 | **Илдар Юзеев.** “Бакчачы турында баллада”,“Йолдыз кашка турында баллада”. | 3 | | | |
| 25 | **Бсү. Сочинение.** Табигать образларында кеше характерының сыйфатлары | | | 1 | Табигать һәм кеше мөнәсәбәтләрен ачыклау. |
| 26 | **Ә.Фәйзи —”Тукай”** романы (өзекләр). | 4 | | | Тарихи-биографик жанр төшенчәсе. |
| 27 | **ДТУ. Л.Шагыйрьҗан.** “Тукай тавышы” поэмасы. | | 1 | | Поэма жанры үзенчәлекләре. |
| 28 | **Бсү. Сочинение** Габдулла Тукай образын гәүдәләндергән сәнгать әсәрләре. | | | 2 | |
| 29 | Арадаш аттестация. | | | 1 | Тестлар башкару |
| | Ел буена үтелгән материалны гомумиләштереп кабатлау. | 1 | | | |
| | | 58 | 4 | 8 | |

**УКУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМЕНӘ, ЭШ ОСТАЛЫГЫНА ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРЕНӘ ТАЛӘПЛӘР**

Татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучы:

- сүз сәнгатенең образлы табигатен;
- милли әдәбиятның иң билгеле язучыларыннан Г.Тукайның, Г.Камалның, Г.Ибраһимовның, Ф.Әмирханның, Г.Исхакыйның, М.Җәлилнең, Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗатының тәп фактларын;

- өйрәнелгән әсәрләрнең эчтәлеген;
- сүз сәнгатенең образлы асылын;
- төп әдәби-теоретик төшенчәләрне **белергә**;
- әдәби әсәр эчтәлеген кабатлап, аерым өлешләрен яттан сәйләү;
- әдәби әсәрне әдәбият теориясеннән мәгълүматлар файдаланып анализлау;
- әдәби әсәрнең аерым якларын элементларын җентекләп тикшерү һәм нәтиҗәләр чыгару;
- әдәби әсәрнең төр һәм жанрын билгеләү;
- әдәби әсәрләрне, аларның геройларын чагыштыру;
- геройларга характеристика бирү, автор позициясен ачыклау;
- сәнгатьле уку;
- әдәби әсәрләр хакында төрле характердагы иҗади эшләр башкару

**күнекмәләрен** үзләштергән булырга тиеш.

Укучыларның уку барышында алган белем-күнекмәләрен бәяләп бару укыту процессының мөһим өлешен тәшкил итә, аның әһәмияте, максаты укучыларның белемнәрен даими күзәтеп, бәяләп бару белән билгеләнә.

**Уку** күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр: әдәби текстны аңлап, дөрес, йөгерек һәм сәнгатьле уку, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес интонация һәм басым белән уку, текстның төп мәгънәсен, эчтәлеген аңлап, эчтән уку һәм кирәкле информацияне табу һ.б.

**Сөйләм** күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр: әсәрнең эчтәлеген бәян итү яки тәкъдим ителгән аерым өзекләрен яттан сөйләү, әсәрнең геройлары, вакыйгалары турында текст төзеп, хикәяләп сөйләү, бирелгән темага хикәя төзеп сөйләү, язучының биографиясе, язучы иҗаты хакында сөйләү, әсәргә карата үз мөнәсәбәтен җиткерү, автор текстына нигезләнгән монологик сөйләм әзерләү, аерым әсәрләр, әдипләр, әдәби күренешләр һ.б. хакында сөйләшү.

**Язу (язма сөйләм культурасын)** күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр: әдәби әсәр буенча куелган сорауларга язмача җавап әзерләү, әсәргә мөстәкыйль бәяләмә, сочинение элементлары белән изложение, сочинение һәм әсәргә яки билгеле бер темага мөнәсәбәтле хикәяләр һ.б. язу.

**Анализ күнекмәләрен һәм теоретик белемнәрне** бәяләү өчен биремнәр: әсәрнең төр һәм жанр үзенчәлекләрен табу, геройларга, образлар системасына бәя бирү, автор һәм хикәяләүченең вазифасын ачыклый алу, образларның мәгънәләрен табу, стиль, тел-сурәтләү чараларын табу һәм тексттагы функциясен билгеләү, сюжет барышын тикшерү, сюжет элементларын табу, тема-проблема, идеяне билгеләү, әдәби әсәрдәге вакыйгаларны һәм геройларны чагыштыру һ.б.

Әлеге бирем төрләреннән тыш, укучыларның белем, күнекмәләрен тикшерү максатыннан тестлар, тест тибындагы биремнәр куллану да уңышлы санала. Тестларның уңайлылыгы аларны тикшерү эшен тиз, төгәл оештырырга, дөрес һәм дөрес булмаган җавапларны чагыштырырга мөмкинлек бирә, моннан тыш, укучыга татар әдәбиятыннан бердәм дәүләт (республика) имтиханына әзерләнү барышында да ярдәм итә ала.

**Формалаштырылырга тиешле белем-күнекмәләр (уку елы башына)**

- Сүз сәнгатенең образлы табигате турында күзаллау булу.

- Классик әдипләребезнең тормыш һәм иҗат юлларыннан төп фактларны белү.
- Өйрәнелгән төп әдәби-теоретик төшенчәләрне белү.
- Әдәби текстның сюжетын сөйли белү.
- Өйрәнелә торган әсәрнең аерым эпизодын (яисә күренешне) анализлый алу.
- Әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклый белү.
- Әдәби әсәрләрне чагыштыра белү.
- Әдәби әйтелеш таләпләрен саклаган хәлдә өйрәнелгән әсәрләрне сәнгатьле итеп уку.
- Өйрәнелгән әсәргә дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтеңне белдерү.
- Диалогта яисә бәхәстә катнашу.
- Сүз сәнгатенең аерым күренешләре белән мөстәкыйль танышу һәм аларның эстетик кыймматен бәяләү (класстан тыш вакытта әсәр укуга ихтыяҗ булу).
- Татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү күнекмәсенә ия булу.

**6 нчы сыйныфны тәмамлаганда үзләштерелергә тиешле белем-күнекмәләр**

- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының тәп фактларын истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү;
- геройларга характеристика бирү;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
-җырлар һәм аларның төрләрен аера белү;
-хикәя,фантастик хикәяне аера белү;
-шигырь һәм поэманың үзенчәлекләрен белү;
-уңай герой, лирик герой төшенчәләрен аера белү;
-әдәби әсәрләрдән сурәтләү чараларын таба белү;
-милли орнаментларны аера белү.
-төп әдәби-теоретик төшенчәләр;

## ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

Урта сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предмет нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

*Танып-белү өлкәсендә*:

- аерым төр һәм жанрга караган әсәрләрне аңлап укый һәм кабул итә, эчтәлеген кабатлап (аерым очракларда текстны яттан) сөйли, кирәк чакта текстстан өзекләр китерә алуга ирешү;
- укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алуына, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеруына ирешү;
- укучының классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белүе;

- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгарып, укыган буенча тезислар һәм план төзү, геройларга характеристика бирү, сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен билгеләү күнекмәсе булдыру;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашырга, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

*бәяләү өлкәсендә*:
- милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәтү;
- әдәби әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт һәм бәя булдыру;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүенә ирешү;
- автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.

*эстетик яктан*:
- әдәби әсәрнең образлы табигате хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булдыру, аның эстетик кыйммәтен тою хисе тәрбияләү;
- баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;
- рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү.

Бүгенге яшүсмер укучы алдагы буын укучылардан нык аерыла, телевидение, радио, интернет һ.б. бик күп мәгълүмат чаралары тирәлегендә үскән һәм тәрбияләнгән бала бай мәгълүматлы була, әмма еш кына әлеге мәгълүматлар аның рухи дөньясына тискәре йогынты да ясый. Шуңа күрә **шәхси нәтиҗәләр** арасында түбәндәгеләре аерым әһәмияткә ия:
- укучының җаваплылык хисен активлаштыру;
- укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәт булдыру;
- баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү;
- төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү.

Урта сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предметара нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:
- укучыларда әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре ярдәмендә мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну формалаштыру;
- татар теленә бәйләнештә, туган телнең матурлыгына һәм байлыгына хөрмәт тәрбияләү;
- мәдәниятара бәйләнешләрне саклау, укучының башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү.

**Гомуми төп мәктәбенең 5-9 нчы сыйныфларында укучыларның ана теленнән белем, осталык һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары:**

**Уку күнекмәсен тикшерү һәм бәяләү:**
5 нче сыйныфта – 100 - 110 сүз,
6 нчы сыйныфта – 110 – 120 сүз
7 нче сыйныфта – 130 – 140 сүз
8, 9 нчы сыйныфларда – 140 – 150 сүз
Сочинение бәяләү нормалары

| | *Эшнең эчтәлеге һәм теле* | *Грамоталылыгы* | *Билге* |
|---|---|---|---|
| 1 | Эчтәлек темага туры килә; язмада фактик ялгышлар юк;план (яки плансыз) эзлекле язылган;теле бай, образлы, стиль бердәмлеге сакланган | 1 орфографик яки пунктуацион (яки грамматик) хата бар | “5”ле куела |
| 2 | Язманың эчтәлеге темага туры килә, ул дөрес ачылган; 1 фактик хата җибәрелгән, хикәяләү эзлеклелелегендә артык әһәмияте булмаган бозу сизелә;тулаем алганда, теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган | 2 орфографик,1 пунктуацион (яки1 грамматик) хата бар | “4”ле куела |
| 3 | Эчтәлекне бирүдә мөһим читләшүләр бар: ул нигездә дөрес, ләкин фактик төгәлсезлекләр очрый, хикәяләү эзлекле түгел; телнең ярлылыгы сизелеп тора; синонимик сүзләрне аз куллана, бертөрлерәк синтаксик төзелмәләр файдалана, образлы түгел, сүз куллануда ялгышлар җибәрә; стиль бердәмлеге сакланып җитмәгән. | 3 орфографик,2 пунктуацион 1 грамматик хата бар | “3”ле куела |
| 4 | Тема ачылмаган; фактик төгәлсезлекләр күп, планга туры килми, эзлеклелек бозылган; теле ярлы; сүз куллану ялгышлары еш очрый; стиль бердәмлеге юк. | Орфографик хаталарның саны 3тән, пунктуацион хаталарның саны 2дән, грамматик хаталарның саны 3 тән артык | “2”ле куела |
| 5 | Төгәлсезлекләр билгесе “2”ле кую нормасыннан артып китә. | Төгәлсезлекләр “2”ле кую нормасыннан артып китә. | “1”ле билгесе куела |

**Уку барышында үтелергә тиешле фонетик, орфоэпик, пунктуацион, грамматик таләпләрнең үтәлешенә нигезләнеп, бәяләр куелырга мөмкин.**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1 | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>- фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>- татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) сакланса;<br>- җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр – иҗекләргә, җөмлә - | “5”ле билгесе куела. |

| | | |
|---|---|---|
| | сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>- тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә куелса,<br>- интонацион яктан тексттагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;<br><br>Укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирелсә; | |
| 1<br>2 | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектәукылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфоэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә, ягъни:<br>- кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә;<br>- сөйләмнең структур бүленешендәкайбер хаталар булса;<br>- җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрелсә;<br><br>Укытучының сорауларына төгәл җавап бирелсә; | “4”ле билгесе куела. |
| 1<br>2<br>3 | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлекләр булса; | “3”ле билгесе куела. |
| 1<br>2<br>3<br>4 | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап алынганда. | “2”ле билгесе куела. |

**Методлар һәм технологияләр**

6 нчы сыйныфта, әлеге эш прораммасын тормышка ашырганда, аңлату-күрсәтү; репродуктив, проблемалы укыту методы, өлешчә эзләнү (эвристик) методлар кулланыла; үстерелешле укыту технологиясе, ИҮТ кулланыла.

**Тематик планлаштыру**
Татар әдәбияты
**6 класс**

**Укытучы** Нәҗметдинова Ләлә Әсхәт кызы
**Сәгатьләр саны** **70**
**Атнага 2 сәгать.**
**Контроль дәресләр- 2 , Иншалар язу -8 сәгать;**
**Административ контроль дәресләр- 1 сәгать.**
**Дәрестән тыш уку- 4 сәгать.**
**Тематик планлаштыру —**Татар телендәгомуми төп белем бирү мәктәпләре (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа" (Төзүче-авторлары: Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. Казан, 2013) **нигезендә төзелде.**
**Дәреслек:** Ф.Ә.Ганиева, М.Д.Гарифуллина. Әдәбият. 6 сыйныф. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014 ел

**Өстәмә әдәбият**

1. Әдәбият теориясе. Ф.Хатипов.Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2000.
2. Әдәбият белеме сүзлеге. А.Г.Әхмәдуллин.. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1990.
3. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма . Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева.-Казан: Мәгариф, 2005
4. Әдәбият дәресләрендә бәйләнешле сөйләм үстерү: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-6нчы сыйныфларында эшләүче укытучылар өчен кулланма. Я.Х.Абдрәхимова.-Казан: Мәгариф,2007.

5.Әдәбият дәресләре. А.Г.Яхин. Казан, "Мәгариф", 2005

**КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН**

| № | **Дәрес темасы** | **Дәрес тибы** | **Үзләштерелгән материал буенча көтелгән нәтиҗәләр** | **Контроль төрләре** | **Укучылар эшчәнлегенә характеристика** | План | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | **Мифлар.-3 сәг.** Дөньяны үзләштерүнең беренче баскычы буларак **мифология**. | Жанр белән танышу. | Миф жанры турында белемнәргә ия булу, | 5 нче биттәге сорауларга җавап бирү | Мифларның тематикасын билгеләү, характерын ачыклау. | 04.09 | |
| 2 | Мифлар белән танышу. «Алып кешеләр», «Җил иясе җил чыгара» мифлары. | Әсәр белән танышу. | Әсәрләрнең эчтәлеген белү. | Мөстәкыйль эш | Әсәрне уку, тыңлау һәм анализлау. | 06.09 | |
| 3 | Дөнья халыклары тудырган мифлар һәм татар халкы иҗат иткән мифлар. | Әсәрләр белән танышу | Әсәрләрнең эчтәлеген белү. | Мөстәкыйль эш | Әсәрне уку, тыңлау һәм анализлау | 11.09 | |
| 4 | **Практик дәрес. Тема: Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма.-2 сәг.** | Теоретик материаллар белән танышу. | Образлар системасын өйрәнү, әдәби алымнар, тел-сурәтләү чараларын билгеләү. | сорауларга җавап бирү | Әдәби әсәрләрне анализлау | 13.09 | |
| 5 | **Практик дәрес. Тема: Әдәби әсәр**. Образлар системасы. Әдәби алымнар, тел-сурәтләү чаралары. | Теоретик материаллар белән танышу. | Образлар системасын өйрәнү, әдәби алымнар, тел-сурәтләү чараларын билгеләү. | сорауларга җавап бирү | Әдәби әсәрләрне анализлау | 18.09 | |
| 6 | **К.Насыйриның «Әбүгалисина» повесте.- 4 сәг.** | Әсәр белән танышу. | Әсәрләрнең эчтәлеген белү,фантастик әсәр жанры турында мәгълүматлы булу. | Мөстәкыйль эш. | Әсәрне уку, тыңлау һәм анализлау. Нәтиҗәләр ясау. | 20.09 | |
| 7 | К.Насыйриның «Әбүгалисина» повестен уку, анализ. Хыялый хикәя. | Хыялый хикәя. | Әдәби әйтелеш таләпләрен саклаган хәлдәәсәрне сәнгатьле итеп укый белү, кыскартып сөйләү. | Эчтәлекне анализлау | Әсәрне уку, тыңлау һәм анализлау | 25.09 | |
| 8 | Эпик төр жанры буларак хикәя белән уртаклыгы, аермасы. | Әсәр белән танышу | Әсәрне сәнгатьле итеп укый белү, кыскартып сөйләү. | Эчтәлекне анализлау | Нәтиҗәләр ясау. | 27.09 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Тасвирланган вакыйгалар, күренешләр. Төп геройлар, ярдәмче персонажлар, җыелма образлар. **Практик дәрес. Тема:** Образларга чагыштырма бәяләмә бирү | Әсәр белән танышу | Әсәрне сәнгатьле итеп укый белү, кыскартып сөйләү. | Эчтәлекне анализлау | Нәтиҗәләр ясау. | 02.10 | |
| 10 | **Бсү. К. Насыйриның «Әбүгалисина» повесте буенча язма эш башкару.** “Әбүгалисина белән Әбелхарис язмышыннан мин нинди нәтиҗәләр ясадым? “ | язма эш башкару | Әдәби әйтелеш таләпләрен саклаган хәлдә әсәрне сәнгатьле итеп укый белү, кыскартып сөйләү. | Эчтәлекне анализлау | Әсәрне уку, тыңлау һәм анализлау | (4)09.10 | |
| 11 | **Г.Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе.-5 сәг.** | Әсәр белән танышу | Төп геройның менәзенә бәяләмә бирү. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. Дәфтәрләрдә мөстәкыйль эш. | Әдип тормышы һәм иҗат юлы буенча укытучы сөйләвен кабул итү, әңгәмәдә катнашу. Әсәрне уку һәм анализлау | 11.10 | |
| 12 | БСҮ. «Алмачуар» повестеннан өзекне яттан сөйләү. | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Атлар турындагы өзеккә салынган мәгънәне аңлау һәм аның әдәби вазифасын билгели алу. | Өзекне яттан сөйләү | Сәнгатьле сөйләүне бергәләп бәяләү. | 16.10 | |
| 13 | Г.Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясен уку, анализ. | Әсәрне анализлау | Төп герой менәзенә бәяләмә бирү. | Өзекне яттан сөйләү | Индивидуаль | 18.10 | |
| 14 | «Алмачуар» әсәрен өйрәнүне йомгаклау. | Әсәрне анализлау | Әсәргә карата дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтеңне белдерә белү. | Сорауларга җавап бирү | Әсәр буенча фикер алышу оештыру, төп геройларга характеристика бирү, әңгәмә-бәхәстә | 23.10 | |
| 15 | **Г.Рәхимнең «Яз әкиятләре» хикәясе.-2 сәг.** Эпик жанр - хикәя. | Әсәр белән танышу | Әсәрләрнең эчтәлеген аңлауга ирешү. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. | Әсәрне сәнгатьле уку. | 25.10 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Г.Рәхимнең «Яз әкиятләре» хикәясе. Образ, символ, деталь, аллегория. Табигать образы, әйбер образы.Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. | Әсәр белән танышу | Әсәргә карата дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтеңне белдерәбелү. | Сорауларгра җавап бирү Образ, символ, деталь, аллегория төшенчәләрен аңлату. | Әсәрне сәнгатьле уку. | 30.10 | |
| 17 | **Дәрдемәнднең** шигырьләре**.-2сәг.** «Видагъ»,“Каләмгә хитаб” | Әдип биографиясе белән танышу | Дәрдемәнднең тәрҗемәи хәле турында мәгълүматлы булу. Әсәрнең эчтәлеген аңлау. Әсәргә карата дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтеңне белдерә белү. | Сорауларга җавап бирү. | Әдип тормышы буенча укытучы сөйләвен кабул итү, әңгәмәдә катнашу. Әсәр буенча фикер алышу | 01.11 | |
| 18 | Дәрдемәнднең замандаш шагыйрьләр арасында үзенчәлекле урын алган фәлсәфи лирикасы. | Әсәрләре белән танышу | Әсәргә карата дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтеңне белдерә белү. | Сорауларга җавап бирү. | Анализлау, фикер алышу. | 13.11 | |
| 19 | **Сәгыйть Рәмиев – нечкә күңелле лирик.-2 сәг.** | Әдип биографиясе белән танышу. | С.Рәмиевнең тормыш юлын аңлау, аның иҗатына лиризм хас булуны төшенү. | Сорауларга җавап бирү. | Әдип тормышы буенча укытучы сөйләвен кабул итү, әңгәмәдә катнашу. | 15.11 | |
| 20 | С.Рәмиевнең “Уку”, “Авыл”, “Мин” шигырьләре. | Әсәр белән танышу | С.Рәмиевнең шигырьләренең эчтәлеген аңлау. | Сәнгатьле укуны бергәләп бәяләү. | С.Рәмиевнең шигырьләрен сәнгатьле итеп укып фикер алышу, эчтәлеген аңлау өстендә эшләү. | 20.11 | |
| 21 | **Галиәсгар Камал – күренекле драматург.** -4 сәг. “Беренче театр”комедиясе | Әдип биографиясе белән танышу. | Г.Камалның татар театрын үстерүгә керткән өлешен аңлау. | Сәнгатьле укуны бергәләп бәяләү. | Әдип тормышы буенча укучылар һәм укытучы сөйләвен кабул итү, әңгәмәдә катнашу. Әсәрне | 22.11 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | рольләргә бүлеп уку. | | |
| 22 | Г.Камал “Беренче театр”- көлке ситуациягe корылган вакыйга . | Әсәр белән танышу | Әдәби әйтелеш таләпләрен саклаган хeлдe әсәрне сeнгатьле итеп укый, әсәргe карата дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтеңне белдерә белү. | Сәнгатьле укуны бергәләп бәяләү. | Әсәрне рольләргә бүлеп уку, видеязма (өзек) карау һәм анализлау. | 27.11 | |
| 23 | Г.Камал “Беренче театр” комедиясе. Конфликт турында төшенчә. | Әсәр белән танышу | Әсәрнең эчтәлеген һәм ни өчен комедия икәнен аңлау, комедия турындагы белемнәрне киңәйтү. Төп образларның үзенчәлекле сыйфатларын белү. Искелек гәүдәләнеше буларак Хәмзә образына бәя бирә алу. | Әсәр буенча сорауларга җавап бирү. | Әсәрне рольләргә бүлеп уку һәм анализлау | 29.11 | |
| 24 | Хикәяләү һәм шигъри сөйләмнән аермалы буларак, әсәр теленең диалог һәм монологларга корылган булуы. | Әсәр белән танышу | Төп образларның үзенчәлекле сыйфатларын белү. | Әсәр буенча сорауларга җавап бирү. | Әсәрне анализлау. | 04.12 | |
| 25 | **Г.Тукайның «Исемдә калганнар» истәлеге.-5 сәг.** | Әсәр белән танышу | Г.Тукай биографиясен тагын бер кат искә төшерү, ныгыту. Әсeр эчтәлеге аша Тукай язмышының төрле борылышларга бай булуын, бу борылышларның халык язмышына бәйлелеген күрсәткән ситуация һәм вакыйгаларны аңлау һәм аңлата белү. | Мөстәкыйль эш | Әсәрне уку һәм анализлау. | 06.12 | |
| 26 | Г.Тукайның «Исемдә калганнар» истәлеге. Автобиографик әсәр. | Автобиографик әсәр. | Г.Тукай биографиясен тагын бер кат искә төшерү, ныгыту. Әсәр эчтәлеге аша Тукай язмышының төрле борылышларга бай булуын, бу борылышларның халык язмышына бәйлелеген күрсәткән ситуация һәм вакыйгаларны аңлау һәм аңлата белү. | Сорауларга җавап бирү. | Әсәрне уку һәм анализлау. | 11.12 | |
| 27 | Г.Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрен өйрәнүне дәвам иттерү | | | | Әсәрне уку һәм анализлау. | 13.12 | |
| 28 | Г.Тукайның «Исемдә | Әсәр белән | | Сорауларга | Әсәрне уку һәм | 18.12 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | калганнар» әсәрен өйрәнүне дәвам иттерү | танышу | Әдәби телнең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү күнекмәсенә ия булу. | җавап бирү, мөст. эш. | анализлау. | | |
| 29 | Г.Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрен өйрәнүне йомгаклау. | Әсәр белән танышу | | Мөстәкыйль эш | Әсәрне анализлау. | 20.12 | |
| 30 | **БСҮ. Сочинение.** “Бәләкәй Апуш ничек зур Тукай булды?” | контроль дәрес. | | Сочинение. | “Тукай” романына нигезләнеп, сочинение язу. | 25.12 | |
| 31 | БСҮ. Сочинениеләрне бергәләп уку, тикшерү. Хаталар өстендә эш. | Хаталар өстендә эш. | Бәйләнешле текст төзү күнекмәсе алу. | Сочинение. | Хаталар өстендә эш башкару. | 27.12 | |
| 32 | **Практик дәрес.**Тема: Лирик әсәрне анализлау. | Әсәрләр белән танышу. | Лирик әсәрне анализлау, әдәби алымнарны эзләү. | Сорауларга җавап язу. | Анализ алымнарын кулланырга өйрәнү. | 15.01 | |
| 33 | **Практик дәрес.** Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). | Теоретик төшенчәләрне тексттан табу. | Тел–стиль чараларын (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар) табу күнекмәләре. | Мөстәкыйль эш | Анализ алымнарын кулланырга өйрәнү. | 17.01 | |
| 34 | **Һ. Такташ – батыр йөрәкле әдип. -4 сәг.** | Әдип биографиясе белән танышу | Әдипнең тормыш юлына карата соклану хисләрен белдерә алу. | Сорауларга җавап бирү | Әдип тормышы буенча укытучы сөйләвен кабул итү, әңгәмә оештыру | 22.01 | |
| 35 | Һ. Такташ «Пи-би-бип» шигыре. | Әсәр белән танышу | Шагыйрьнең биографиясен тагы искә төшерү, ныгыту. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү | Әдип тормышы буенча әңгәмә оештыру. Әсәрне шагыйрь биографиясе белән бәйләп күрсәтү | 24.01 | |
| 36 | Һ. Такташ. “Урман” , ”Болай | Әсәр белән | Мөстәкыйль уку һәм анализлау | Әсәр эчтәлеге | Тезмә әсәрләргә | 29.01 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | гади җыр гына”. | танышу | алымнарына төшенү. | буенча сорауларга җавап бирү | анализ ясау күнекмәләре ясау. | | |
| 37 | Һ. Такташ шигырьлә-рендә лирик герой, образлар системасы, сурәтләү чаралары. | Әсәрлԑрне анализлау. | Мөстәкыйль уку һәм анализлау алымнарына төшенү. | Мөстәкыйль эш | Анализ алымнарын кулланырга өйрәнү. | 31.01 | |
| 38 | **И.Газиның «Кояш артыннан киткән тургай”** хикәясе.-3 сәг. | Әсәр белән танышу | Әдипнең иҗат үзенчәлекләрен өйрәнү. | Сорауларга җавап бирү | Чәчмә әсәрләргә анализ ясау күнекмәләре ясау. | 05.02 | |
| 39 | Хикәя төзелеше. | Яңа тема үзләштерү. | Әсәр төзелеше турында белемнәрне кулланырга өйрәнү. | Гамәли күнекмәләр ясау. | Сюжет-композиция төшенчәләрен әсәрдә аңлату. | 07.02 | |
| 40 | **«Кояш артыннан киткән тургай”** хикәясендә сурәтләү обьекты, хикәяләүче образы, сурәтләү алымнары. | Әсәрне анализлау | Әсәрнең эчтәлеген аңлауга ирешү. | Әсәр эчтԑлеге буенча сорауларга җавап бирү | Чәчмә әсәрләргә анализ ясау күнекмәләре ясау. | 12.02 | |
| 41 | **ДТУ. И.Гази**. “Өч Мәхмүт” хикәясе. | Мөстәкыйль уку һәм анализлау алымнарына төшенү. | Мөстәкыйль уку һәм анализлау алымнарына төшенү. | Эчтәлекне уку һԑм сөйләү. | Әсәр буенча фикер алышу | 14.02 | |
| 42 | **Р.Батулланың «Имче» хикәясе.-4 сәг.** | Әсәр белән танышу | Әсәрнең эчтәлеген аңлауга ирешү. | Эчтәлекне уку һәм сөйләү. | Әсәрне уку һәм фикер алышу | 19.02 | |
| 43 | Р.Батулланың «Имче» әсәрен анализлау. | Әсәр герое турында төшенчәне үзләштерү. Үзәк геройның шуклыгы, хаталары, холкы турында фикер йөртә белү. | Әсәр герое турында төшенчәне үзләштерү. Үзәк геройның шуклыгы, хаталары, холкы турында фикер йөртә белү. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү | Әсәр буенча фикер алышу | 21.02 | |
| 44 | Р.Батулланың «Көчек» әсәре. | Әсәр белән танышу | Әсәрдә тема-проблема чишелешен бирүдә автор ысулы. | Әсәр эчтԑлеге буенча сорауларга | Чәчмә әсәрләргә анализ ясау. | 26.02 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | җавап бирү. | | | |
| 45 | Р.Батулланың «Чагыр» әсәрен анализлау. | Әсәр белән танышу | Үзәк геройның холкы турында фикер йөртәбелү. | Әсәрне уку һәм эчтәлек сөйләү. | Әдип тормышы буенча укучылар һәм укытучы сөйләвен кабул итү, әңгәмәдә катнашу | 28.02 | |
| 46 | **БСҮ. Р.Батулланың** «Имче» әсәренә нигезләнеп сочинение язу. | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Әдәби телнең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү күнекмәсенә ия булу. | Сочинение. | Р.Батулланың «Имче» әсәренә нигезләнеп сочинение язу | 05.03 | |
| 47 | **Ф.Яруллинның “Ак төнбоек”** хикәясе**.- 3 сәг.** | Әсәр белән танышу | Үзәк геройның холкы турында фикер йөртә белү. | Әсәрне уку һәм эчтәлек сөйләү | Әдип тормышы буенча укучылар һәм укытучы сөйләвен кабул итү, әң-гәмәдә катнашу. Чәчмә әсәрләргәанализ ясау. | 07.03 | |
| 48 | Вакыйга, геройлар. Конфликт һәм сюжет этаплары. | Әсәрне анализлау | Әсәрдә тема-проблема чишелешен бирүдә автор ысулын билгеләү. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. | Чәчмә әсәрләргә анализ ясау | 12.03 | |
| 49 | Ф.Яруллинның “Ак төнбоек” хикәясендә хикәяләү алымнары. | Әсәрне анализлау | Әсәр герое турында төшенчәне үзләштерү. Үзәк геройның хаталары, холкы турында фикер йөртә белү. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. | Әсәр буенча фикер алышу. | 14.03 | |
| 50 | **ДТУ. Ф.Яруллин.** “Урман әкияте” хикәясе. | Әсәрне анализлау | Әсәрдә тема-проблема чишелешен бирүдә автор ысулын билгеләү. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. | Чәчмә әсәрләргә анализ ясау күнекмәләре ясау | 19.03 | |
| 51 | **Р.Миңнуллин шигырьләре.- 3 сәг.** “Шундый минем туган ягым”, “Кайтыйк ла үзебезгә!”шигырьләрендә | Әсәрләр белән танышу, анализлау. | Тематикасын билгеләү, язу үзенчәлекләрен ачыклау. | Жанр төре буенча анализлау . | Тезмә әсәрләргә анализ ясау күнекмәләре ясау. | 21.03 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тема уртаклыгы. | | | | | | |
| 52 | ”Энекәш кирәк миңа!”, “Әни, мин көчек күрдем” шигырьләрендә образлар бирелеше. | Әсәрләр белән танышу, анализлау. | Әсәр герое турында төшенчәне үзләштерү. Үзәк геройның хаталары, холкы турында фикер йөртә белү. | Сорауларга җавап бирү, сәнгатьле уку. | Лирик герой образы, аның хис-кичерешләре турында фикер алышу. | 02.04 | |
| 53 | Р.Миңнуллин шигырьләрендә балачакны гәүдәләндергән образ-лар. | Әсәрне анализлау. | Мөстәкыйль уку һәм анализлау алымнарына төшенү. | Сәнгатьле уку, сорауларга җавап бирү, | Әсәр геройлары һәм лирик герой образы, аларның хис-кичерешләре турында фикер алышу. | 04.04 | |
| 5 | **М.Җәлил. «Сандугач һәм чишмә»** балладасы.-2 сәг. | Әсәр белән танышу, анализлау. | Символик образлар бирелешен ачыклау, баллада жанрына хас сыйфатларны билгеләү. | Сәнгатьле уку, эчтәлекне сөйләү. | Әсәр геройлары һәм лирик герой образының үзенчәлекләрен аңлата белү. | 09.04 | |
| 55 | М.Җәлилнең тормыш юлы белән танышу, иҗаты турында гомуми мәгълүмат бирү. | Әсәрне анализлау. | Баллада турында башлангыч мәгълүматлы булу, әсәр белән таныш булу, балладага анализ ясау тәртибе белән таныш булу. | Индивидуаль биремнәр үтәү. | Балладага анализ ясау күнекмәсе булдыру | 11.04 | |
| 56 | **ДТУ.М.Җәлил**. “Ана бәйрәме” шигыре | Әсәр белән танышу, анализлау. | Образлар бирелешен ачыклау, баллада жанрына хас сыйфатларны билгеләү. | Мөстәкыйль эш | Шигъри формадагы әсәрләрнең эчтәлеген сөйли белү | 16.04 | |
| 57 | **Илдар Юзеев. -3 сәг.** “Бакчачы турында баллада”. | Әсәр белән танышу, анализлау. | Баллада турында мәгълүматларны тулыландыру, балладага анализ ясау күнекмәсен камилләштерү. | Сәнгатьле уку, эчтәлекне сөйләү. | Әсәр геройлары һәм лирик герой образы, аларның хис-кичерешләре турында фикер алышу. | 18.04 | |
| 58 | Илдар Юзеев. “Йолдыз кашка турында баллада”. | Әсәр белән танышу, сән- | Символик образлар бирелешен ачыклау, баллада жанрына хас | Сәнгатьле уку, эчтәлекне | Балладага анализ ясау күнекмәсе | 23.04 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | гатьле уку, анализлау | сыйфатларны билгеләү. | сөйләү. | булдыру | | |
| 59 | Баллада- лиро-эпик жанрдагы әсәр. Аның төп үзенчәлекләре. | Язучы иҗатын анализлау. | Образлар системасы: таби-гать, тереклек, кеше образларының эстетик мәгънәләре, роле. Кискен каршы-лыкка, уйланмалылыкка корылган булу, вакыйгалар хәрәкәте һәм конфликтның үзенчәлекле чишелеше | Мөстәкыйль эш: сорауларга җавап бирү. | Символ һәм аллегория алымнарын билгеләү. | 25.04 | |
| 60 | Бсү. Сочинение.<br>Табигать образларында кеше характерының сыйфатлары (Г.Рәхимнең “Яз әкиятләре”, мәсәлләр һәм балладалар мисалында). | Бәйләнешле сөйләм үстерү, контроль дәрес. | Әдәби телнең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү күнекмәсенә ия булу. | Сочинение. | Балладаларга нигезләнеп, сочинение язу. | 30.04 | |
| 61 | **Ә.Фәйзи иҗаты.-**4 сәг. | Язучы иҗатын анализлау. | Язучы иҗаты турында мәгълүмат бирү. | Индивидуаль биремнәр үтәү. | Автобиографик һәм биографик әсәрләр аермасын табарга өйрәнү | 02.05 | |
| 62 | Тукайның тормыш юлын өйрәнү һәм романның язылу тарихы**.** | Әсәрнең язылу тарихы белән танышу. | Язучы турында мәгълүматлы булу. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. | Әсәрне уку, тыңлау һәм анализлау. Нәтиҗәләр ясау. | 07.05 | |
| 63 | Ә.Фәйзи “Тукай” романы (өзекләр). | Әсәр белән танышу | “Исемдә калганнар” әсәре һәм Г. Тукайның тулы биографиясе белән бәйләп нәтиҗәләр ясау. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. | Әсәрне уку, тыңлау һәм анализлау. Нәтиҗәләр ясау. | (9)14.05 | |
| 64 | Ә.Фәйзи “Тукай” романында төп образ бирелеше. | Әсәр белән танышу, анализлау. | “Исемдә калганнар” әсәре һәм Г. Тукайның тулы биографиясе белән бәйләп нәтиҗәләр ясау. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. | Әсәрне уку, тыңлау һәм анализлау. Төп образга бәяләмә бирү. | 16.05 | |
| 65 | “Тукай” романына анализ. | Тулы анализ. | Г. Тукайның биографиясе белән бәйләп нәтиҗәләр ясау. | Әсәр эчтәлеге буенча сорауларга | Әсәрне анализлау. Төп образга бәяләмә бирү. | 16.05 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | җавап бирү. | | | |
| 66 | ДТУ. Л.Шагыйрьҗан. “Тукай тавышы” поэмасы. | Әсәр белән танышу, сәнгатьле уку, анализлау | Жанр үзенчәлеге турында мәгълүматлы булу. | Сәнгатьле уку, эчтәлекне сөйләү. | Язучы иҗатына бәяләмәбирү. | 21.05 | |
| 67 | **Бсү. Сочинение** Габдулла Тукай образын гәүдәләндергән сәнгать әсәрләре. | Бәйләнешле сөйләм үстерү. контроль дәрес. | Әдәби телнең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү күнекмәсенә ия булу. | Сочинение. | Алган мәгълүматларга ларга нигезләнеп, сочинение язу. | 23.05 | |
| 68 | Арадаш аттестация контроль эше. Тестлар башкару. | контроль | Тулы курс буенча белемнәрне барлау. | Тестлар | Тестлар башкару. | 28.03 | |
| 69 | Б/с. Хаталар өстендә эш. | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Белемнәрне барлау, хаталарны бетерү өстендә эшләү. | Сорауларга җавап бирү | Хаталар өстендә эш | 30.05 | |
| 70 | Ел буена үтелгән материалны гомумиләштереп кабатлау. | Кабатлау. | Гамәли дерес | Сорауларга җавап бирү | Материалны гомумиләштерә белү. | 30.05 | |

**Укыту-методик комплекты**

| Укытучы өчен методик әдәбият | Укучылар өчен әдәбият |
|---|---|
| 1.Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Т.Ш. Гыйләҗев. Татар әдәбияты. Теория. Тарих. К.: “Мәгариф” нәш-ты, 2004<br>2. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. К.: ТКН, 2000.<br>3. Гайфуллина Ф.А.Әдәбият дәресләрендә .Казан, «Яңалиф», 2006<br>4. Хөснетдинова Л.К. Әдәбият укыту мәсьәләләре. Яр Чаллы, 2000.<br>5. Мифтахова М.А. Мәктәптә Хәсән Туфан иҗаты. Алабуга, 2002.<br>6. Ф.К.Мифтиева, Ф.Г.Галимуллин. Рус мәктәбенде татар балаларына әдәбият укыту. 6нчы сыйныф. Укытучылар өчен методик кулланма. Казан. Мәгариф. 2001<br>7. Абдрәхимова Я.Х. Әдәбият дәресләрендә мөстәкыйль һәм иҗади эшләр. К.: “Мәгариф”<br>8. Абдрәхимова Я.Х. Әдәбият дәресләрендә бәйләнешле сөйләм үстерү. К.:. Мәгариф, 2007.<br>9. Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары. Библиографик белешмә. К.: ТКН, 1986.<br>10. Татар әдебияты тарихы. 6 том. 60-90 еллар әдәбияты. К.: “Раннур нәшрияты, 2001.<br>11. Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В.Р. Әдәби әсәргә анализ ясау.К.: “Мәгариф” нәшрияты, 2005. | 1. Әдәбият белеме сүзлеге.<br><br>2. Галиуллин Т.Н. Шигърият баскычлары. К.: “Мәгариф”, 2002.<br>3. Җәләлиева М.Ш. Әдебиятыбызның җырлы чишмәләре. К.: “Мәгариф”, 2001.<br>4. Җәләлиева М.Ш. Әдәбиятта тойгы катламнары. К.: “Мәгариф”, 2005.<br>5. .Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында. К.: “Мәгариф”, 2006.<br>6. .Программа буенча каралган язучыларның әсәрләре<br>7. “ Ялкын” журналы, “Сабантуй”газетасы |

| | |
|---|---|
| 12..Гайфуллина Ф.Ә. Әдәбият дәресләрендә. К.:. “Яңалиф” н-ты, 2006.<br>13.Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында. К.: “Мәгариф”, 2006.<br>14. Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В.Р. Әдәби әсәр өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз.<br>К.: “Мәгариф” нәшрияты, 2007.<br>15. «Фән һәм мәктәп», «Мәгариф». | |